ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2015, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2016, № 11; 2017, № 7, № 12; 2018, № 12; 2019, № 7 – 8; 2020, № 4; 2021, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 87 статьяның 6 өлешендә «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы)» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый

актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законы)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 90 статьяның 2[1] өлешендә «www.» хәрефләрен төшереп калдырырга;

3) 92 статьяның 3 өлешендәге 10 пунктында «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 94 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 95 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Фикер алышу закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектның закон проекты турындагы докладыннан һәм җаваплы комитетның өстәмә докладыннан башлана. Әгәр закон проектын Дәүләт Советы каравына әзерләү берничә комитетка йөкләнгән булса, җаваплы комитетның концепциясе бәяләмәсе белән килешмәгән башка комитетларның докладлары да тыңлана. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиешле закон проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының җайга салу йогынтысын бәяләү турында тискәре бәяләмәсе алынган очракта, җаваплы комитетның өстәмә докладында закон

проектына карата тискәре искәрмәләрнең булуы әйтелергә һәм аларга карата комитетның дәлилләнгән фикере белдерелергә тиеш.»;

6) 126 статьяның 6 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

7) 20 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

8) 30 бүлекнең исемендә «һәм Татарстан Республикасы Конституция судына» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 173 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Конституциясенең 125 статьясы нигезләмәләре, «Россия Федерациясе Конституция Суды турында» 1994 елның 21 июлендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон (алга таба – «Россия Федерациясе Конституция Суды турында» Федераль конституциячел закон) нигезендә Дәүләт Советы үз карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе Конституция Судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

б) 2 өлештә «яисә Татарстан Республикасы Конституция судына» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 174 статьяда:

а) 1 өлештә «яисә Татарстан Республикасы Конституция судына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «яисә Татарстан Республикасы Конституция судына», «, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 175 статьяда «яисә Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 190 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен Дәүләт Советына үз эшчәнлеге турында доклад җибәрә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары

буенча вәкаләтле вәкил ел саен Дәүләт Советына үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешен бәяләү, шулай ук аларның хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәр булган доклад җибәрә.»;

13) 191 статьяда:

а) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 15 пунктта «, Татарстан Республикасы Конституция судына» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2021 елның 24 декабре
№ 1281-VI ДС